| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 с. Лебяжье № 112

**Чикләүләрне һәм тыюларны,
мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу
яисә җайга салу турындагы таләпләрне
һәм коррупциягә каршы көрәшү максатында
билгеләнгән вазыйфаларны
үтәмәгән өчен җәза куллану тәртибе
турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

“Коррупциягә каршы көрәшү турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәүгә контрольне камилләштерү максатында Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы 3 август, 2018 ел, 307-ФЗ санлы Федераль закон кабул итү уңаеннан

Лебяжье авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге Советының 21 декабрь, 2012 ел, 36 нче санлы карары белән расланган чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу исә җайга салу турындагы таләпләрне һәм коррупциягә каршы көрәшү максатында билгеләнгән вазыйфаларны үтәмәгән өчен җәза куллану тәртибе хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2 март, 2007 ел, 25-ФЗ санлы Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 нче матдәләрендә каралган җәза җирле үзидарә органы җитәкчесе (эш бирүче) тарафыннан кулланыла:

1) Лебяжье авыл җирлегеҗирле үзидарәсе органында коррупция һәм башка хокук бозуларны булдырмау өчен җаваплы кадрлар хезмәтенең хезмәт урынындагы кешеләре үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;

2) Муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарында үз-үзләрен тотуга карата таләпләрен үтәү һәм Лебяжье авыл җирлегемәнфәгатьләр конфликтын җайга салу (әгәр тикшерү нәтиҗәләре турында доклад комиссиягә җибәрелсә) буенча комиссия тәкъдимнәре;

3) Коррупцион хокук бозулар турында коррупция һәм башка хокук бозуларны булдырмый калу буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады, анда аның чынлыкта эшләнүе һәм муниципаль хезмәткәрнең аның ризалыгы белән генә һәм ул коррупцион хокук бозуларны таныган очракта (ышанычны югалту уңаеннан эштән азат итү рәвешендә җәза кулланудан тыш) язма гаризасы бәян ителә.
4) Муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;
5) Муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән таләпләрне, тыюларны һәм чикләүләрне исәпкә алып башка материаллар.

2. Әлеге карарны Алексеевск шәһәр җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль**
**районы Лебяжье авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Б.Зверев**